**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru


ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

31.05.2024 № ПР-92

2024 елның су коену сезоны чорында Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының ачык сулыкларында су коенуны тыю турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Актаныш муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссия күрсәтмәсе нигезендә, Актаныш муниципаль районы территориясендә пляжлар һәм сулыкларда гражданнарның иминлеген тәэмин итәрлек башка оештырылган күпләп ял итү урыннары булмау сәбәпле, гражданнарның гомерен һәм сәламәтлеген саклау максатларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2024 елның су коену сезоны чорында Актаныш муниципаль районы территориясендә урнашкан ачык сулыкларда гражданнарның су коенуын тыярга.

2. 2024 елгы су коену сезоны чорында Актаныш муниципаль районы су тирәсендәге объектларда халыкның күпләп ял итү урыннарында рейдларны профилактикалау өчен мобиль төркем составын расларга (кушымта).

3. 1 июньнән (су коену сезоны башлангач) су объектлары янында гражданнарның күпләп ял итү урыннарын, шулай ук авыл җирлегендә урнашкан сулыкларны тикшерү буенча мобиль төркемнәрнең эшен активлаштырырга;

4. Авыл башкарма комитетлары җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:
- су коену сезоны дәвамында җирлек территориясендә ачык сулыкларда коенуны тыю турында халык белән аңлату эшләре алып барырга һәм белешмәлекләр тапшырып, балаларны аерым контрольдә тотарга;
- балаларның өлкәннәр ягыннан күзәтүсез һәм караучысыз булган гаиләләрне махсус контрольгә алырга, мондый гаиләләр белән индивидуаль профилактик эш алып барырга, ата-аналарга имза куйдырып, коенуны тыю турында белешмәлекләр тапшырырга;
- ачык сулыкларда бу урында су коенуны тыю сәбәпләре турында тулы мәгълүмат белән ике телдә су коенуны тыю турында аншлаглар куярга (төбенең рельефы, суның биологик составы һ.б.).

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

6. «2023 елның су коену сезоны чорында Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының ачык сулыкларында су коенуны тыю турында» 2023 елның 25 маендагы ПР-76 номерлыТатарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының карары үз көчен югалткан дип танырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Л.Р. Сираева

Кушымта

Татарстан Республикасы
Актаныш муниципаль районы

Башкарма комитеты карары

___ ____№___ белән расланган

2024 елның су коену сезоны чорында Актаныш муниципаль районының су объектларында халык күпләп ял итә торган урыннарда профилактик рейдлар өчен мобиль төркем составы

Зарипова А.И. - Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының административ комиссиясе секретаре, оештырылган мобиль патруль төркемнәренең эшен контрольдә тоту өчен Башкарма комитетның җаваплы вазыйфаи заты;

Мортазин И.М.-Актаныш янгын-коткару гарнизоны башлыгы (килешү буенча);

Минһаҗев М.Р. – Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы (килешү буенча);

Шакирова Р.М. - ТР Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының "Мәгариф идарәсе" МКУ башлыгы (килешү буенча);

Нургалиев И.И. - Актаныш муниципаль районының "ОСВОД" РОО җитәкчесе (килешү буенча);

Актаныш муниципаль районы авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча).